ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«10» ноябрь **2020 ел** **№ 876**

**2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 нче карарына һәм Арча муниципаль районы Уставына яраклаштырып, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. 2021 елга:

кушымта итеп бирелгән Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарын;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Т.Мөхәммәтшинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р.Мөхәррәмов

Арча муниципаль районы башкарма комитетының 10 ноябрь 2020 ел, № 876 карары белән расланган

## Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территория ягыннан урнашуы | Норматив чыгымнар (бер укучыга елына, сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | иртә һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |